Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Данауровка авыл җирлеге Советы
карары

09.06.2023 ел №36/1

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
«Данауровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге
Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында»гы 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Данауровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 84 - 86 статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Данауровка авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Данауровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 13 статьяның 12 пунктында «Җирлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «тавыш бирүне әзерләүне һәм уздыруны оештыручы сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 19 статьяда:

4 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Халык алдында тыңлаулар уздыру вакытын һәм урынын күрсәтеп, гавами тыңлаулар уздыру турында мәгълүмат, шулай ук гавами тыңлауларга чыгарыла торган муниципаль норматив хокукый акт проекты гавами тыңлаулар үткәрү көненә кадәр 7 календарь көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында яисә җирлекнең торак пунктлары территориясендә махсус мәгълүмат стендларында, шул исәптән Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылырга, шулай ук «Бердәм дәүләт порталы һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылырга тиеш.»;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Гавами тыңлаулар һәм муниципаль норматив хокукый акт проекты басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көннән башлап, җирлек халкы халык

тыңлауларына чыгарылган муниципаль норматив хокукый акт проекты яисә мәсьәләсе буенча, шул исәптән «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы ярдәмендә, тәкъдимнәр һәм искәрмәләр җибәрергә хокуклы.

Җирлек башлыгы кергән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне гомумиләштерүне оештыра һәм аларны гавами тыңлауларда катнашучыларга җиткерә.»;

9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында яисә Җирлек торак пунктлары территориясендә махсус мәгълүмат стендларында урнаштырылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш, шул исәптән Чистай муниципаль районының рәсми сайтында һәм “Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы” федераль дәүләт мәгълүмат системасында гавами тыңлаулар уздырганнан соң 5 көннән дә соңга калмыйча урнаштырылырга тиеш.»;

1.3. 28 статьяның 7 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) » сүзләренә алмаштырырга;

1.4. 38 статьяга түбәндәге эчтәлекле 2.1 пункт өстәргә:

«2.1. Җирлек Советы депутаты җитди сәбәпләрсез алты ай рәттән җирлек Советының оештырылган бар утырышларында булмаган очракта, җирлек Советы карары белән җирлек Советы депутатының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатыла.»;

1.5. 40 статьяның 1 пунктының икенче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) » сүзләренә алмаштырырга;

1.6. 44 статьяның 4 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;

1.7. VII бүлек үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.

3. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Данауровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына кертелгән үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне дәүләт теркәвеннән соң билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Данауровка авыл җирлеге башлыгы А.В.Сашин